ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТУЙМА АВЫЛЫ ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ

КАРАР

15 ноябрь 2024 ел № 2

2025 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең Туйма
авылында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. "2025 елда үзара салымны Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары уку йортларының һәм урта махсус уку йортларының көндезге бүлеге студентларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан салымны 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә.

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Туйма авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру).

2. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Туйма авылында насос сатып алу).

3) Торак пункт территориясен төзекләндерү (аварга торган агачларны кисү);

4) һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнар һәйкәле тирәсендә киртә тоту).

3. Әлеге карарны Туйма авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Енабердино авыл җирлеге” бүлегендә (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Җыенда рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Ю.Скворцова